| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**01.09.2020** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1611** |

2013-2017 елларда гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү программасы буенча Зеленодольск муниципаль районында авария хәлендә дип танылган һәм сүтелергә тиешле күпфатирлы йортларны сүтү турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 31 декабрендәге 2425 номерлы «Зеленодольск муниципаль районы күпфатирлы йортларны авария хәлендә дип тану турында»гы карары, «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 16 декабрендәге 3622 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районында 2013-2017 елларга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программага үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2017 елның 06 февралендәге 176 номерлы карары нигезендә, йортлар күчерелгәнлеген истә тотып, Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Торак кодексына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Кушымта итеп бирелә торган йортларны сүтелергә тиешле дип танырга.
2. «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» МКУ күрсәтелгән йортларны сүтү һәм биналарны сүткәннән соң төзелеш чүп-чарын утильләштерү буенча муниципаль контрактны үтәү эшен оештырырга.
3. «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ Зеленодольск районы муниципаль милек реестрыннан йортларны билгеләнгән тәртиптә төшереп калдыруны тәэмин итәргә.
4. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы Р.З. Хаҗиевка әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыруны яки «Зеленодольская правда»газетасында бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
карарына кушымта
01.09.2020 № 1611

| | |
|---|---|
| 1 | Зеленодольск шәһ., Декабристлар ур., 9 й. |
| 2 | Зеленодольск шәһ., Декабристлар ур., 13 й. |